| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.02.2019 г.Казань № 76

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 26 февралендә 5439 номеры белән теркәлде

2019 елда бер экспертиза субъектына карата хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырган өчен түләү күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 216.1 статьясы, «Хезмәт шартларын махсус бәяләү турында» 2013 елның 28 декабрендәге 426-ФЗ номерлы федераль законының 24 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 12 августындагы 549н номерлы, «Хезмәт шартларын махсус бәяләү сыйфатына экспертиза уздырган өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләр раслау турында» 2014 елның 9 октябрендәге 682н номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 елның 11 июнендәге 431 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. 1 нче номерлы кушымтага туры китереп, 2019 елда бер экспертиза субъектына карата хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырган өчен түләү күләмен расларга.
2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) хезмәт сагы буенча дәүләт идарәсе бүлеген, хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыруга вәкаләтле итеп билгеләргә.
3. Билгеләргә:

- хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында, хезмәт шартларына экспертиза объекты булып андагы хезмәт шартларына карата хезмәт шартларына махсус бәяләү уздырылган эш урыны санала;
- хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырган өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү Министрлыкка хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру турында гариза тапшырыдганчыга кадәр Татарстан Республикасы бюджетына акча күчерү юлы белән, нал булмаган формада гамәлгә ашырыла.

4. Хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырган өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан акча күчерү өчен банк реквизитларын 2 нче кушымтага туры китереп билгеләргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.Ф.Вәлиуллловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 4 февралендәге 76 номерлы карарына 1 нче кушымта

2019 елда хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасының бер объектына карата түләү күләме

| № п/п | Эшләр төре | Эш урыннары саны, берәмлек | Бер эш урынына түләү күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру | 1 - 5 | 10 959,52 |
| | | 6 - 50 | 16 439,28 |
| | | 50дән артык | 21 919,04 |
| 2. | Эш урынын (эш урыннарын) тикшерүне гамәлгә ашыру өчен эш урыннарына чыгып (тәүлеклекләрне һәм яшәүне исәпкә алып), хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру | 1 - 5 | 40 685,99 |
| | | 6 - 50 | 61 028,98 |
| | | 50дән артык | 81 371,97 |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 4 февралендәге 76 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартлары буенча дәүләт экспертизасына түләү реквизитлары**

**Алучы:** Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (ш/сч 04112001150)

**Алучының ИНН:** 1657069000

**Алучының КПП:** 165701001

**Исәп-хисап счеты:** 40101810800000010001

**Банк:** Бүлек – Татарстан Республикасы МБ, Казан ш.

**БИК:** 049205001

**ОКТМО:** теркәлү урыны буенча үз шәһәре (районы)

**Керем буенча бюджет классификациясе коды:** 716 1 13 01992 02 0000 130

**Түләүнең билгеләнеше:** Хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырган өчен